**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**БЕДЕНЬГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИДӘҢГЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

тел. (84373) 50-5-40, факс 50-5-40

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

-

**29 октябь 2019 ел** **№ 1**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Бидәңге авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсенә нигезләнеп, **КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 12 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Бидәңге төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе бинасында Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыены оештырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бидәңге авыл җирлегенең Татар Бидәңгесе торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм

аннан алынган акчаларны  җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерүгә сез риза буласызмы:

- Татар Бидәңгесе авылы эчендәге Ленин ур., К.Маркс ур., М.Җәлил ур. юлларны төзекләндерү;

- Татар Бидәңгесе авылы зиратына капка сатып алу һәм урнаштыру;

- Татар Бидәңгесе авылында һәлак булган сугышчыларга куелган обелискны төзекләндерү (койма кую)?».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бидәңге авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештырырга һәм уздырырга.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бидәңге авыл җирлеге башлыгы** **Р.М. Хусаинов**